| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БОГДАШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БОГДАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Рус<br>Богдашкиносы<br>авылы | **КАРАР** |

«30» октябрь 2019 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенә керүче Рус Богдашкиносы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Богдашкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны 2019 елның 10 ноябрендә Богдашкино авылы мәдәният йортында (Рус Богдашкино авылы, Совет урамы, 26 нчы йорт ) 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны 2019 елның 17 ноябрендә Богдашкино авылы мәдәният йортында (Рус Богдашкино авылы, Совет урамы, 26 нчы йорт ) 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны 2019 елның 20 ноябрендә Богдашкино авылы мәдәният йортында (Рус Богдашкино авылы, Совет урамы, 26 нчы йорт ) 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Рус Богдашкино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны 2019 елның 24 ноябрендә Богдашкино авылы мәдәният йортында (Рус Богдашкино авылы, Совет урамы, 26 нчы йорт ) 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Рус Богдашкиносы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегенә керүче Рус Богдашкиносы авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, студентлардан, көндезге уку формасы буенча укучылардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм таш түшәү (сатып алу, ташу, җәю) )

« РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А.Л. Михайлова